**Мәсгут Имашев**

# КЫР КАЗЛАРЫ АРТЫННАН

*Спектакльләр өчен җырлар*

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2013

УДК 782
ББК 85.317
И48

**Имашев, М. Г.**
Кыр казлары артыннан : спектакльләр өчен җырлар / Мәсгут Имашев. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2013. – 96 б.
ISMN 979-0-9003056-3-3

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, композитор Мәсгут Имашевның бу җыентыгына авторның спектакльләр өчен язылган әсәрләре туплап бирелде.

УДК 782
ББК 85.317

ISMN 979-0-9003056-3-3

© Татарстан китап нәшрияты, 2013
© Имашев М. Г., 2013

## Авылым күле

*(Х. Ибраһим. «Газиз ярым» спектакленнән)*

*Хәбир Ибраһим* сүзләре

Авыл күле тирән икән,
Чумганнарым булмады.
Бу хәсрәтләр килер диеп
Уйлаганым булмады.

*Кушымта:*
Ялгыз үрдәк йөзә күлдә,
Шаулый бөдрә тал.
Газиз ярым, назлы җырым
Булып мәңге кал.

Белмәгәнмен кадереңне,
Соңлап кына аңладым.
Бер кайтырмын, дип киттең дә
Кайта гына алмадың.

*Кушымта.*

Иртән торып сулар сибәм
Бакчамдагы гөлемә.
И Ходаем, сабырлык бир
Алда килер көнемә.

*Кушымта.*

## Ак чәчәкләр бүләк иттең

*(Х. Ибраһим. «Газиз ярым» спектакленнән)*

*Хәбир Ибраһим* сүзләре

Ак чәчәкләр бүләк иттең,
Яме калды бүлмәмдә.
Белмим кая киткән юлың,
Бәлки, бүтән күрмәм дә.

Ак чәчәкләр бүләк иттең,
Икәү бергә булганда.
Яннарымда беркем дә юк,
Ялгыз күңелем тулганда.

Ак чәчәкләр бүләк иттең,
Өзелеп калды бәхетем.
Ялгыз итсә итсен язмыш,
Өзелмәсен өметем.

## Ана сагышы

*(Г. Зәйнашева. «Язмышлар һәм ялгышлар» спектакленнән)*

## Әфганчылар җыры

*(Г. Зәйнашева. «Язмышлар һәм ялгышлар» спектакленнән)*

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре

Әфганстан иле – таулар иле,
Кая барма – кайнар кыя таш.
Кыяларга газиз башын куеп,
Кыяларга газиз башын куеп,
Корбан булды күпме ватандаш.

Безнең өскә янар таулар ауды,
Безнең башка ялкын, ут яуды.
Безне көткән әткәй-әнкәйләрнең,
Безне көткән әткәй-әнкәйләрнең
Йөрәгенә кара кан сауды.

Исән калганнар – без кайттык илгә,
Янар таулар калды еракта.
Еллар үтсә дә булмый онытып,
Еллар үтсә дә булмый онытып,
Ачы нәфрәт яши йөрәктә.

## Балыкчы җыры

*(Һ. Сафина. «Җыр дәвам итә» спектакленнән)*

*Һава Сафина* сүзләре

Уятып кояшны таңда,
Йоклатып Чулпанны назлап,

Аннан-моннан кабып алып,
Томан-тунны иңгә салып,
Мин чыгам юлга.

Шомырт юлга чәчәк сибә,
Йомшак җилләр биттән үбә,
Чык тамчысы күзен кыса,
Тал-тирәкләр иңнән коча,
Һай, рәхәт дөнья!

Арган чакта, талган чакта,
Ярсып йөрәк янган чакта,
Иркәм, гафулар итсәнә,
Балык сәламләп китсә дә,
Ял була миңа.

**Бер сукмак салыр идек**

*(Ф. Яруллин. «Кызлар күңеле – тирән сер» спектакленнән)*

*Фәнис Яруллин* сүзләре

Йөзләреңдә яшьлек яме,
Күзкәйләрең сөрмәле.
Күзләреңә яшеренгән
Мәхәббәтнең серләре.

Күзләреңдәге серләрне
Гел укыр, армас идем.
Күңелеңдә ниләр барын
Аңламый калмас идем.

Синең күздән минем күзгә
Күпме нур күчәр иде.
Ике күңел арасында
Чәчәкләр үсәр иде.

Шул чәчәкләр арасыннан
Бер сукмак салыр идек.
Серле мәхәббәт илендә
Мәңгегә калыр идек.

**Гашыйклар тавы**

*(И. Юзеев. «Гашыйклар тавы» спектакленнән)*

*Илдар Юзеев* сүзләре

Ниндидер моңнар бар,
Ниндидер шомнар бар
Каеннар, имәннәр шавында.
Онытыйк шомнарны,
Каршылыйк таңнарны
Бергәләп Гашыйклар тавында.

Без тауның башында,
Мәңгелек каршында –

Гашыйклар очрашкан урында.
Җанда ай нурлары,
Хисләр саф, югары –
Биектә, Киек Каз Юлында.

Син әле янымда,
Хушлашу таңында
Сүз бирик изге җир алдында:
Айрылган көннәрдә
Булыйк гел үрләрдә,
Булыйк гел Гашыйклар тавында.

**Гүзәлия җыры**

*(Г. Ахунов. «Утлар яна учакта» спектакленнән)*

*Сажидә Сөләйманова* сүзләре

Таң атканда уйланам,
Су акканда моңланам.
Таң нурында син йөзәсең,
Утларыңда мин янам.

Биек тауга менимме,
Агымсуга керимме?
Дусларыма сөйлим микән,
Үзем генә белимме?

Таулар текә, су тирән,
Тирән булса да керәм.
Ерак икәнең дә беләм,
Нигәдер якын күрәм.

**Далам – туган бишегем**

*(А. Балакаев. «Ана йөрәге» спектакленнән)*

*Мәхмүт Хөсәен* сүзләре

Туган җире,
Туган иле
Тик бер була кешенең.
Синдә тудым,
Улың булдым,
Далам – туган бишегем.

Юлым якты,
Суым татлы,
Күңелем – тургай даласы.
Яшим, янам,
Бәхет табам
Синдә мин – ил баласы.

Миһербанлы,
Сизгер җанлы
Ватан-анам – син, далам.
Иң сөекле,

Игелекле,
Зәңгәр күкле киң далам!

**Җиләккә бармам инде**

*(И. Юзеев. «Гашыйклар тавы» спектакленнән)*

*Илдар Юзеев* сүзләре

Җиләккә дип барган идем,
Юри генә адаштым.
Сине күргәч, сүзсез калдым,
«Адаштым» дип алдаштым.

Синең йөргән юлларыңда
Җиләкләрем түгелде.
Салкын каравыңны белгәч,
Күңелләрем сүрелде.

Җиләкләргә бармам инде.
Бармам инде, адашмам.
«Җиләклектә адаштым», – дип
Инде бүтән алдашмам.

**Закир җыры**

*(Я. Ялунер. «Казан кызы» спектакленнән*)*

*Клара Булатова* сүзләре

Яна йөрәк, кая барыйм?
Җанга ничек тынгы табыйм?
Түгел кичә – бүген генә,
Күптән давыл күңелемдә.

Бәлки, йөрәк шулай янып
Әвреләдер күмерләргә.
Беркем белми янганымны,
Тыштан сабыр күренгәнгә.

Яна йөрәк, кая барыйм?
Җанга ничек тынгы табыйм?
Сулар сибеп тә сүрелмәс,
Ярсый йөрәк, кая барыйм?

* Татарчага Г. Әхмәтҗанов һәм Г. Хөсәенев тәрҗемәсендә.

**Зәкия җыры**

*(Г. Зәйнашева. «Гайфи бабай, өйлән давай!..» спектакленнән)*

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре

Йөгереп төштем таңда су буена,
Ялгыз аккош канат кагына.
Канатларым өзелеп,
Бәгырьләрем сызылып,

Әллә кемне күңел сагына.

Җәйге кичтә карыйм зәңгәр күккә,
Ай нурлана, йолдыз кабына.
Еллар буе көтеп, кавышу өмет итеп,
Әллә кемне күңел сагына.

**Зөлфия җыры**

*(К. Әмиров. «Зөлфия» спектакленнән)*

*Кәшиф Әмиров* сүзләре

Син килдең,
Көтмәгәндә килдең,
Күңелемә ут салдың,
Ут салдың,
Ут салдың.
Айдыр син,
Йолдыздыр син.

Караңгы төнне
Яктыртып,
Яктыртып,
Күңелемә
Нурлар салдың син.
Күңелемә
Моңнар салдың син.

Син килдең,
Көтмәгәндә килдең,
Күңелемә ут салдың,
Ут салдың,
Ут салдың.
Ай булдың,
Йолдыз булдың.

Караңгы
Төнне яктыртып,
Күңелемә аккан нур булдың,
Күңелемнән аккан моң булдың...

**И яна ла йөрәгем...**

*(Ш. Шаһгали. «Пожар» спектакленнән)*

*Шамил Шаһгали* сүзләре

И ага су, ага су ла,
Болгана су, алалмыйм.
И яна ла йөрәккәем,
Дәваларын табалмыйм.

Күңел тулса, җырлап булмый,
Җырламый елап булмый.
Җырламыйча, еламыйча,
Йөрәккә чыдап булмый.

Атлар киләдер юл буйлап,
Казлар килә су буйлап.
Йөзләремне сары алды,
Төрле хәсрәтләр уйлап.

**Йөрәгеңә якын итсәң...**

*(Һ. Сафина. «Җыр дәвам итә» спектакленнән)*

*Һава Сафина* сүзләре

Серле карашларың белән
Ник сихерләдең?
Сихерләдең, ләкин үзең
Шуны белмәдең.

Сөюемне күңелемдә
Озак сакладым.
Чөнки сиңа җиткерергә
Җаен тапмадым.

Хисләремне көйгә салам,
Бәлки, аңларсың...
Йөрәгеңә якын итсәң,
Бергә җырларсың.

**Йөрәк җыры**

*(Г. Ахунов. «Утлар яна учакта» спектакленнән)*

*Саҗидә Сөләйманова* сүзләре

Тиңләр өчен серле күзләреңә,
Күк йөзеннән йолдыз эзләдем.
Гөлләр сибеп йөрдем эзләреңә,
Ятка калырсың дип белмәдем.

Янсын йөрәк, янсын әйдә дөрләп!
Ялкыннары берәр сүрелер.
Янган мәхәббәтем очкыннары
Йолдыз булып күккә сибелер.

Караңгыда юллар эзләрсең дә
Йолдызларга карап табарсың.
Сызылып кына йолдыз атылганда,
Өзелеп сөюемне аңларсың.

**Каерылмасын канатым**

*(Р. Батулла. «Каерылмасын канатым» спектакленнән)*

*Рөстәм Мингалим* сүзләре

Мин бәхетле идем,
Якты көнле идем,
Күз алдыма басты кара төн.

Аерыласызмыни,
Каерыласызмыни,
Әткәм-әнкәм – ике канатым?

Китеп ике якка,
Сез аерылган чакта,
Мин ялгызым калырмынмыни?
Инде сездән башка
Ялгыз калган башка
Кайгы-хәсрәт алырмынмыни?

Рәхәт үсәр идем,
Ерак очар идем,
Кайтыр идем сагынып дәшсәгез.
Үтсен кара төннәр,
Кайтсын якты көннәр,
Бәхетемне җилгә чәчмәгез!

**Кайтыр идем**

*(Р. Хәмид. «Кайтыр идем» спектакленнән)*

*Мансур Шиһапов* сүзләре

Кайтыр идем туган авылыма,
Күрер идем моңсу ярларын.
Аланында сузылып,
Сузылып, кырын ятып
Тыңлар идем камыш шауларын.

Чылтырап аккан чишмәләрнең җырын
Тыңлар идем басып ташына.
Кайтыр идем, авылым,
Туган авылым, сиңа,
Кайтыр өчен йөрәк ашкына.

Кайтыр идем туган авылыма,
Буйлар идем елга буйларын.
Бик сагындым, авылым,
Туган авылым, сине,
Сиңа кайта һаман уйларым.

**Каһарманнар**

*(Ш. Рәкыйпов. «Таңнар һаман матурмы?» спектакленнән)*

*Госман Әхмәтҗанов* сүзләре

Туган илдә алсуланып
Матур таңнар ата микән?
Көзен киткән сандугачлар
Язын кабат кайта микән?
Бакчаларда – алмагачлар,
Кырда иген үсә микән?
Җәйге таңда тугайларга
Энҗе чыклар төшә микән?
Энҗе чыклар төшә таңда,

Язын кабат кошлар кайта.
Кайтмый бары каһарманнар,
Ил сагында калган алар.

Идел талгын ага микән?
Ярларына кага микән?
Нәниләрнең күзләрендә
Шатлык нуры яна микән?
Ярлар сөйгән ярсу җаннар
Кавышып бәхет таба микән?
Туган илдә алсуланып
Матур таңнар ата микән?
Идел кага ярларына,
Гөлләр калка, бәхет арта.
Язлар булып, таңнар булып
Каһарманнар илгә кайта.

**Кемгә салыйм башны таңнарда?..**

*(К. Финн. «Мәхәббәт хакына» спектакленнән*)*

*Гариф Ахунов* сүзләре

Көтмәгәндә килде бу кайгылар,
Көтмәгәндә килде бу сагыш.
Күңелемдә минем әрнү, ярсу,
Ник аяусыз икән бу язмыш?

*Кушымта:*
Ник ашыктым, үземә тиңне
Ник табалмадым?
Дусларымнан тик бер киңәш
Ник сорамадым?

Дәрья суы ярсып чайкалганда,
Дулкыннары кага ярларга.
Синнән башка кешем юк шул,
Кемгә салыйм башны таңнарда?

*Кушымта.*

* Татарчага Г. Ахунов тәрҗемәсендә.

**Көймәдә**

*(Х. Вахит. «Рәхим итегез!» спектакленнән)*

*Нури Арсланов* сүзләре

Күтәр күңелләремне,
Ки алсу күлмәгеңне.
Кисәң алсу күлмәгеңне,
Алалмыйм күзләремне.

Әйдә утыр көймәгә,
Карама су тирәнгә.
Суларда дулкын тирбәлә,
Дулкынланам сөйгәнгә.

Сулары ла сулары,
Көймәдә барулары,
Көймәләрдә барган чакта
Йөрәкнең янулары!

Үзәкләрем өзелә,
Бәгырем, белмисең генә.
Таңга – Чулпан,
Айга – Зөһрә,
Миңа шатлык син генә.

**Кулымдагы йөзегем**

*(Т. Миңнуллин. «Яшьлек белән очрашу» спектакленнән)*

*Туфан Миңнуллин* сүзләре

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре эчендә.
Мин бит үзем генә түгел,
Янам синең өчен дә.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре ким түгел.
И дускаем, синнән башка
Яшәве мөмкин түгел.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре – Гыйльфаным.
Сине уйлап, үзәкләрем
Өзелә инде, җаным.

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре – Майбәдәр.
Сине, дустым, онытталмам
Кыямәт көнгә кадәр.

**Күңелләрдә безнең ак хыял**

*(Ф. Яруллин. «Кызлар күңеле – тирән сер» спектакленнән)*

*Фәнис Яруллин* сүзләре

Күңелләрдә безнең ак хыял,
Ашкындырып тора гел алга.
Тапланмаслык булсын гомергә,
Лаек юллар сайлыйк хыялга.

Ак хыяллар ап-ак канатлы,
Күтәрсен ул гел-гел югары.
Кошлар юлы белән янәшә
Узсын безнең гомер юллары.
Хыялларга итмик хыянәт,
Бар хыяллар – яшьлек юлдашы.
Яктылыгы белән саклансын
Гомер таңы – безнең юл башы.

Күңелләрдә безнең ак хыял,
Ашкындырып тора гел алга.
Тапланмаслык булсын гомергә,
Лаек юллар сайлыйк хыялга.

**Кыр казлары артыннан**

*(И. Юзеев. «Кыр казлары артыннан» спектакленнән)*

*Илдар Юзеев* сүзләре

Кыр казлары артыннан
Биеклеккә тартылам.
Хыялыма китәр идем
Кыр казлары артыннан.

Кыр казлары артыннан
Китәр идем, тартынам.
Үз-үземне бәйләгәнмен
Хыялым канатыннан.

Кыр казлары артыннан
Очарга дип талпынам.
Тик очалмыйм, карап калам
Кыр казлары артыннан.

**Мәхәббәттән аерылма**

*(В. Константинов, Б. Рацер. «Игълан буенча өйләнү» спектакленнән*)*

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре

Яшьлек кире кайтмый, диләр,
Кайтмас диеп кайгырма.
Гашыйк бул син – яшәрерсең,
Мәхәббәттән аерылма.

Гашыйк булып, йөгереп йөр
Яшьлек дигән болында.
Тыңла сандугач сайравын,
Оныт картлык турында.

Картайдым димә, гашыйк бул,
Күңелең канатланыр.
Кире кайтмаска китсә дә,
Яшьлегең кабатланыр!

* Татарчага Ә. Гобәйдуллина һәм Н. Нәҗмиев тәрҗемәсендә.

**Мин кызыл гөл булып шытармын**

*(М. Маликова. «Моңнар төште башыма» спектакленнән)*

*Мәдинә Маликова* сүзләре

Гомер җәйләреңне кичкән чакта,

Очар кошлар кебек талпынып,
Синең барыр юлың уртасында
Мин асыл гөл булып балкыдым.

Давыл купты, чатнап яшен сукты, –
Йөрәккәем авыр яралы.
Сизә күңелем: синең үткәнеңдә
Мин сынган гөл булып каламын.

Гөрләп килгәч яңа, якты язлар,
Үтеп киткәч салкын кышларың,
Синең сагыш тулы хәтереңдә
Мин кызыл гөл булып шытармын.

**Нефтьчеләр маршы**

*(Г. Ахунов. «Утлар яна учакта» спектакленнән)*

*Саҗидә Сөләйманова* сүзләре

Җырлап чыгабыз иртән кырларга,
Кырлар, урманнар уяна.
Көч бар беләктә,
Кодрәт йөрәктә –
Кеше бәхеткә юл яра.

*Кушымта:*
Суда йөзәргә,
Күктә очарга,
Галәм серләрен
Ачарга!

Корыч манара аумас җилләрдә,
Күңел омтыла тирәнгә.
Таулар селкенә,
Йөрәк җилкенә,
Максат бер генә – җиңәргә!

*Кушымта.*

Җырлап чыгабыз иртән кырларга,
Кырлар, урманнар уяна.
Утлар кабына,
Нурлар агыла,
Җыр кала туар елларга.

*Кушымта.*

**Нигә килми, әнкәй, хәбәрең?..**

*(К. Әмиров. «Зөлфия» спектакленнән)*

*Илдар Юзеев* сүзләре

Улың киткән якка күзең текәп
Торасыңмы капка төбендә?
Аңлыйм, әнкәй, ямансудыр сиңа
Ялгыз яшәү картлык көнеңдә.

Авыр йөк күтәргән иңнәреңдә
Чайкаламы парлы чиләгең?
Тик торалмас җитез кулларыңда
Бии микән һаман иләгең?

Җылы бияләйләр бәйлисеңме
Тыңлый-тыңлый дөнья хәлләрен?
Хатлар язам, нигә бу арада
Килми, әнкәй, синең хәбәрең?..

**Ник йөрәккә саласың яра?**

*(А. Гыйләҗев. «Ефәк баулы былбыл кош» спектакленнән)*

*Аяз Гыйләҗев* сүзләре

Көлүеңне сөям нурландырып,
Нигә моңланасың бу ара?
Офыклар ак, көннәр, күкләр аяз.
Ник төшәсең авыр уйларга?

Сүзләрең бит һәрчак кайнар иде,
Нигә салкын алар бу ара?
Матур күзкәйләрең кырыс карый.
Ник йөрәккә саласың яра?

**Өзелә үзәгем, өзелә...**

*(Ф. Яруллин. «Кызлар күңеле – тирән сер» спектакленнән)*

*Фәнис Яруллин* сүзләре

Өзелә үзәгем, өзелә,
Кайлардан табыйм соң дәвалар?
Сулышым кагылса гөлләргә,
Гөлләр дә ялкынлап яналар.

Өзелә үзәгем, өзелә,
Йолдызлары сүнде күгемнең.
Кайда соң яп-якты көннәрем,
Ник гамьсез бер сабый түгелмен?

Өзелә үзәгем, өзелә,
Хыялның каерылды канаты...
Нигә соң язмышым күз-яшьнең
Ачысын, тозлысын яңартты?

**Рәшит ариозосы**

*(К. Тинчурин, Г. Зәйнашева. «Назлы кияү» спектакленнән)*

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре

Миңа насыйп Казан кызы,
Кайда соң син, кайда соң син?
Әллә инде җирдә түгел,
Йолдыздамы, айдамы син?

Нинди ялкын, нинди утлар
Йөрәккәемне әрнетә?
Алда мине ниләр көтә,
Язмышымны кем хәл итә?

Кая барсам, ник мин ялгыз,
Язмыш күгем ник сагышлы?
Кем соң аңлар йөрәгемне,
Кем җылытыр бу язмышны?

**Салават җыры**

*(Һ. Сафина. «Җыр дәвам итә» спектакленнән)*

*Һава Сафина* сүзләре

Язгы җилләр исә канат җилпеп,
Күңелләрдә кала эзләре.
Синдә генә таптым
Язгы күктәй якты,
Җанга рәхәт биргән күзләрне.

Язгы кояш якты нурын сибә,
Йөрәкләргә төшә чаткысы.
Синдә генә, иркәм,
Язгы көндәй күркәм
Нурлар сипкән күңел яктысы.

Язгы яңгыр тәрәзәмне кага,
Йөрәкләргә тирән моң сала.
Язлар үтә, үтә,
Язлар үткән саен,
Мәхәббәтем сиңа яңара.

**Сәлим җыры**

*(Я. Ялунер. «Казан кызы» спектакленнән*)*

*Клара Булатова* сүзләре

Таң жырым, уят син,
Иркәләп юат син
Мин эзләп тилмергән
Сагышлы ярымны.
Тирбәлеп таңнарда,
Җиткер син аңарга
Күңелдә төйнәлгән
Бөтен аһ-зарымны.
Таң жырым, уят син,
Иркәләп юат син
Мин эзләп тилмергән
Сагышлы ярымны.

Белсен ул мин барын,
Эзләсен үз ярын...
Сакласын, әйт аңа,

Тик күңел сафлыгын!
Ышансын, белсен ул
Мин килер көн барын,
Чыксын ул каршыма,
Чыксын ул атлыгып.
Белсен ул мин барын,
Эзләсен үз ярын...
Сакласын, әйт аңа,
Тик күңел сафлыгын!

* Татарчага Г. Әхмәтҗанов һәм Г. Хөсәенев тәрҗемәсендә.

### Синең күзләрең

*(Р. Хәмид. «Кайтыр идем» спектакленнән)*

*Мансур Шиһапов* сүзләре

Язгы таң кояшы балкыгач,
Безгә тиң пар чәчәк эзләдем.
Нурланып ачылган бөрене
Мин синең күзләргә тиңләдем.
Шул нурга төренгән
Сихерле чәчәкләр –
Әйтерсең ул синең күзләрең,
Әйтерсең ул синең күзләрең!

Кич җитеп,
йолдызлар калыккач,
Безгә тиң пар йолдыз эзләдем.
Күктәге һәр йолдыз балкышын
Мин синең күзләргә тиңләдем.
Шул моңга төренгән
Тылсымлы йолдызлар –
Әйтерсең ул синең күзләрең,
Әйтерсең ул синең күзләрең!

### Сок буйлары

*(Һ. Сафина. «Җыр дәвам итә» спектакленнән Зәйнәп җыры)*

*Һава Сафина* сүзләре

Кояш баткан чакта, Сок буенда
Синең җырларыңны җырладым.
Сайравыннан туктап, сандугач та,
Сандугач та сагынып тыңлады.

Сокның дулкыннары алып китте
Синең тарафларга моңымны.
Әллә кайтасыңмы туган якка? –
Сок буйлары көтә җырыңны.

Иңнәреңнән кочып, тал-тирәкләр
Минем хисләремне сөйләрләр.
Күзләреңнән үбеп, ал чәчәкләр:
«Ул бит көтте сине», – диярләр.

## Су юлы

*(Н. Әсәнбаев. «Мәхәббәт йолдызы» спектакленнән)*

*Нәҗип Әсәнбаев* сүзләре

Килен булып төштем бу авылга,
Таныш түгел әле күршеләр.
Буй-сынымны сынап карар өчен,
Су юлына алып төштеләр.

*Кушымта:*
Су юлы, су юлы,
Сынатмаммы бу юлы?
Сынатмасам бу юлы,
Сынатмам гомер буе!

Тугайлары ап-ак чәчкә генә,
Су буенда бөдрә каеннар.
Чылтыр-чылтыр аккан чишмәсенә
Сандугачлар кушылып сайрыйлар.

*Кушымта.*

Күңелемә якын су юллары,
Монда минем ярым-канатым.
Рәхмәт сезгә, рәхмәт, әй кешеләр,
Бу якларны мин бик яраттым!

*Кушымта:*
Су юлы, су юлы,
Сынатмаммы бу юлы?
Сынатмасам бу юлы,
Сынатмам гомер буе!
Су юлы, су юлы,
Сынатмам гомер буе!

## Танышулар, кавышулар...

*(Г. Зәйнашева. «Гайфи бабай, өйлән давай!..» спектакленнән)*

*Гөлшат Зәйнашева* сүзләре

Күңелләрдә дулкынлана
Саф хисләрнең дицгезе.
Танышулар, кавышулар –
Мәхәббәтнең нигезе.
Ялгыз башлар зая булып
Үткән гомер җәл бит ул.
Танышулар, кавышулар
Була торган хәл бит ул.

Кошлар да парлы яшиләр,
Ялгыз былбыл сайрамый.
Танышулар, кавышулар
Яшькә, картка карамый.
Ялгыз калдым дип уфтанма,
Буйсынма син язмышка.

Танышулар, кавышулар
Ямь бирә ул тормышка.

Бар ул сөю, бар мәхәббәт,
«Юк» дигән сүзләр ялган.
Танышулар, кавышулар
Пәйгамбәрләрдән калган.
«Җаным» дигән,
«бәгърем» дигән
Өзелеп сөйгән яр бит ул.
Танышулар, кавышулар
Һәр заманда бар бит ул.

**Театр**

*(Ш. Камал. «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектакленнән)*

*Габдулла Тукай* сүзләре

Халыкка дәрсе гыйбрәттер – театр,
Күңелдә йоклаган дәртне уятыр.
Театр яктылыкка, нурга илтә,
Кире юлга җибәрми, уңга илтә.
Театр яктылыкка,
Яктылыкка, нурга илтә.

Театр көлдерәдер, уйнатадыр,
Тагы үткән гомерне уйлатадыр.
Күрерсең анда үз хәлең, көләрсең –
Көләрлек булса, булмаса – еларсың.
Театр яктылыкка,
Яктылыкка, нурга илтә.

Күрерсең тормышың нинди: җитешме?
Җитеш булмаса, кай җире җитешми?
Төзәтерсең шуны, тәкмил итәрсең, –
Шулай шактый белем тәхсил итәрсең.
Театр яктылыкка,
Яктылыкка, нурга илтә.

Мөкаддәс ул, бөек ул, гали зат ул,
Тәмам хөр ул вә бик киң ул, азат ул.
Вә ул дарел-голүм, дарел-әдәптер,
Холыкларны төзәтмәккә сәбәптер.
Театр яктылыкка,
Яктылыкка, нурга илтә.

**Туган ил ул бер генә**

*(Т. Миңнуллин. «Безнең авыл Робинзоны» спектакленнән)*

*Туфан Миңнуллин* сүзләре

Кечкенәдән өйрән яшәү серенә:
Газиз анаң, Туган илең бер генә.
Газиз анаң, Туган илең бер генә лә,
Син кадерле туган-үскән җиреңдә.

*Кушымта:*
Чит илдә син, кем булсаң да, ят кеше,
Үз илеңә, үз җиреңә кайт, кеше.
Лә-лә-лә, лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә, һәй!
Лә-лә-лә, лә-лә-лә, лә-лә-лә-лә, һәй!

Кечкенәдән өйрән яшәү серенә,
Яшәү сере дусларыңның иңендә.
Яшәү сере дусларыңның иңендә лә,
Көчле була дуслары күп ир генә.

*Кушымта.*

Һәрнәрсәнең дөньяда бар үз ише,
Кешеләрсез яши алмый бер кеше.
Кешеләрсез яши алмый бер кеше дә,
Һәрнәрсәнең дөньяда бар үз ише.

*Кушымта.*

**Туган ягым каеннары**

*(И. Юзеев. «Олы юлның каены» спектакленнән)*

*Илдар Юзеев* сүзләре

Туган ягым каеннары калалар инде,
Озатыша баралар инде;
Йөрәгемдә яфракларын яралар инде,
Сагышларга салалар инде.

Каеннарым калмый арттан чабалар инде,
Ерагая баралар инде;
Киткән саен якыная аралар инде,
Сагынудан дәвалар инде.

Туган ягым каеннары калалар инде,
Кемнәр сөеп карарлар инде?
Гомерем буе миңа таба чабарлар инде,
Кайталмыйча калалмам инде.

**Туй күлмәге**

*(Г. Ахунов, М. Шиһапов. «Кошның да үз оясы була» спектакленнән)*

*Мансур Шиһапов* сүзләре

Килү белән язлар, һәр кич назлап,
Пар сандугач җырын тыңладык.
Язлар бәхет бүләк итте безгә,
Туй күлмәген алдык нәкъ шул көздә,
Тик кияргә насыйп булмады.

Мин еш киләм чишмә аккан җиргә –
Яшьлек эзем, татлы хыялга.
Чишмә ага чакрымнарны иңләп,
Минем хисләр без танышкан җирдә,
Ник килмисең, иркәм, шул ярга?

Яшьлегемә кире кайтыр идем,
Кабатланмас булса ялгышлар.
Башкаларны йөрәк кабул итми,
Буй-сыннарың күз алдымнан китми,
Күңелемдә әрнү-сагышлар.

Чишмә җыры бик ямансу була,
Бигрәк моңсу була көзләрен.
Януларым, көюләрем белән
Сагынганда туй күлмәген киям.
...Һәм юлларда була күзләрем.

* Г. Ахуновның «Хәзинә» әсәре буенча.

**Туй такмаклары**

*(Г. Ахунов. «Утлар яна учакта» спектакленнән)*

*Саҗидә Сөләйманова* сүзләре

Аккошлар килерләр безгә,
Эзләрен күлдән эзлә.
Аккошлар юлы шикелле
Ак бәхет килсен сезгә!

Аллар үссен, гөлләр үссен
Гомер юлларыгызда.
Тагын бер биесәк иде
Алтын туйларыгызда.

Бергә яшик, әй туганнар,
Тыныч торсын дөньялар.
Килен-кияү киләчәккә
Матур тормыш коралар.

Аерылмагыз, каерылмагыз,
Пар булсын канатыгыз.
Айга түгел, елга түгел,
Гомергә яратыгыз.

Аккошлар килерләр безгә,
Эзләрен күлдән эзлә.
Аккошлар юлы шикелле
Ак бәхет килсен сезгә!

**Унҗиде яшем**

*(Г. Ахунов, М. Шиһапов. «Кошның да үз оясы була» спектакленнән*)*

*Мансур Шиһапов* сүзләре

Язгы хис белән йөрәк серләшә,
Каеннар шаулый – киләчәк дәшә.
Кулда таныклык, чәчәк бәйләме –
Бу безнең язмыш, яшьлек бәйрәме.

*Кушымта:*

Нәрсәгә тиңлим унҗиде яшем?
Ул – кояш нуры, ул – көчле яшен.
Ул – саф таңнары без барыр юлның,
Туачак моңы без җырлар җырның.

Күктән тулган ай сокланып карый,
Йомшак май җиле чәчләрне тарый.
Бөдрәләр бизи сылу йөзләрне,
Зөһрә йолдыздай нурлы күзләрне.

*Кушымта.*

Әйләнә яшьлек, ургылып яшьни
Бу онытылмас бәхетле кичтә.
Күңелдә – шатлык, йөрәктә – көю,
Беренче хатлар, беренче сөю.

*Кушымта.*

* Г. Ахуновның «Хәзинә» әсәре буенча.

**Ут салдың йөрәгемә**

*(Я. Ялунер. «Казан кызы» спектакленнән*)*

*Клара Булатова* сүзләре

Синең белән бергә генә
Бу язларның яме бар сыман.
Син ут салдың йөрәгемә,
Күңел сыза язгы кан сыман.

Һәркем көлә, уйный, җырлый...
Яз яшәртә кабат җир йөзен.
Бәхетлеләр парлап йөри,
Ә мин ялгыз, һаман берүзем.

Сине көтәм, янда йөртәм
Тугры юлдаш итеп сагышны.
Сине көтәм, өмет итәм,
Бизәрсең дип минем язмышны.

* Татарчага Г. Әхмәтҗанов һәм Г. Хөсәенев тәрҗемәсендә.

**Уф, Алла!..**

*(В. Константинов, Б. Рацер. «Игълан буенча өйләнү» спектакленнән*)*

*Мәхмүт Хөсәен* сүзләре

«Ай, Уралым!» көен ишеттемме,
Уйларымда очам Уфага!..
Үз хәлемне үзем генә беләм,
Эчтән генә янам,
Эчтән генә көям,
Эчтән генә сулам:
«Уф, Алла!..»

Исемә төшсә, күңел әллә нишли,
Йөрәгемә дөрләп ут каба!..
Мин ялгызым, син ялгызың,
Сак белән Сок кебек.
«Уф, Алла!..»

Тизрәк кил, ди иркәм, сөйләшик, ди,
Мәсьәләне салып уртага.
Казаннарга карап ул да, ахры,
Ухылдап тын ала:
«Уф, Алла!..»

Сезнең кала – Урал горурлыгы,
Тел тидереп булмый Уфага.
Казан да бит безнең – Идел күрке,
Ничек ташлыйм аны?!
«Уф, Алла!..»

* Татарчага Ә. Гобәйдуллина һәм Н. Нәҗмиев тәрҗемәсендә.

**Хәмзин җыры**

*(И. Юзеев. «Сандугачлар килгән безгә...» спектакленнән)*

*Илдар Юзеев* сүзләре

Сизми калдым талларыма
Нинди кош кунганлыгын.
Очып киткәч кенә белдем
Сандугач булганлыгын.

Ак самовар борыннары,
Күңелле борулары.
Сиңа ничек, миңа авыр
Аерым торулары...

Чәчең чылбыр, чәчең чылбыр,
Тартып өзәрлек түгел.
Чәчең чылбыр, үзең былбыл,
Күрми түзәрлек түгел...

**Чакыру җыры**

*(Х. Вахит. «Кайда соң син?» спектакленнән)*

*Хәй Вахит* сүзләре

Очраттым мин аны яр өстендә,
Күзләреннән күзем алмадым.
Күңелемнең аны бик күптәннән бирле
Эзләгәнен шундук аңладым.

*Кушымта:*
Сәрия, күз нурым,
Мәңге онытылмас җырым.
Син кайда, син кайда?
Сине эзлим һаман да.

Дөньяның бу кадәр матурлыгын
Беренче кат күрдем шул чакта.
Онытa алмам мәңге, мәңге оныта алмам,
Гомер буе аерым торсак та.

*Кушымта.*

Күңелемнең аны бик күптәннән
Эзләгәнен шундук аңладым.
Утлы йөрәгемнән хисләр ташып чыкты,
Тик үзенә әйтә алмадым.

*Кушымта.*

**Чулпыларым бизи буемны**

*(С. Вилданова. «Чулпы моңы» спектакленнән)*

*Сәрия Вилданова* сүзләре

Сукмакларым борма-борма киткән,
Бормалары саен гөл үскән.
Чишмә юлларында гел моңланам,
Миңа насыйп ярлар кем икән?

*Кушымта:*
Чулпыларым бизи буемны,
Чайпалдырмам көмеш суымны.
Чулпыларым бизи буемны,
Кемнәр эчәр көмеш суымны?

Салкын чишмәләрнең төбе якты,
Кемнәр аңа шулай нур сипкән?
Мөлдерәмә тулы чиләкләрем...
Синең сөйгән ярың кем икән?

*Кушымта.*

Кошлар, сайрап, адымымны саный,
Битләремне назлы җил үпкән.
Йөрәгемдә сиңа урын саклыйм,
Күңелемне ачып кер, иркәм.

*Кушымта.*

**Шәрифҗан җыры**

*(М. Ногман. «Кызыл чәчәк легендасы» спектакленнән)*

*Мостафа Ногман* сүзләре

Урал тауларының, ай, иркене,
Йөзә ак болытлар төркеме.
Исән генә булып, туган илгә
Әйләнәсе иде беркөнне.

Сандугачлар уйный, ай, ояда,
Урал бөркетләре кыяда.
Җаннарыңа якын дуслар белән
Яши алсаң икән дөньяда.

Урал тауларының, ай, иркене,
Йөзә ак болытлар төркеме.
Исән генә булсак, туган илгә
Әйләнербез әле беркөнне.

**Якындагы ерак кешем син**

*(Һ. Сафина. «Җил давылга юрый» спектакленнән)*

*Һафа Сафина* сүзләре

Чәчәк тотып кулларыма,
Чыгам мин юлларыңа.
Тик күпме генә йөрсәм дә,
Тик күпме генә йөрсәм дә,
Өзелеп сагынып көтсәм дә
Килмәссең син,
                    килмәссең син,
Килмәссең...

Каршы ярып давылларны,
Иңгә куеп иңнәрне,
Бер юллардан барсак та без,
Бер юллардан барсак та без,
Бер эзләргә бассак та без,
Ерак шул син...
Ерак шул син...
Бик ерак...

**Яңа ел вальсы**

*(Аманулла. «Кар калада Яңа ел» спектакленнән)*

*Аманулла* сүзләре

Яңа бәхет теләп һәр өйгә,
Җир өстенә Яңа ел килә.
Кар җемелди, күктә ай көлә,
Тәрәзләргә сихри нур иңә.

> *Кушымта:*
> Бары шатлык кына алып килсен
> Яңа елның яңа көннәре.
> Очрашуны көткән гашыйклардай
> Кавышалар сәгать телләре.

Тынып калган бүген буран да,
Утлар яна төнге урамда.
Учларыма килеп куна да
Кар бөртеге эреп югала.

> *Кушымта.*

Тик иминлек телим җиремә,
Тыныч таңнар атсын илемдә.
Сабыйларның шаян көлүе
Яңгырасын өйләр түрендә.

*Кушымта.*

**Яңа елның төне тылсымлы**

*(Аманулла. «Энҗебикә – кар кызы» спектакленнән)*

*Аманулла* сүзләре

Яңа елның төне тылсымлы –
Сихри көмеш нурга коена.
Киләчәккә илтер юлларга
Ак чәчәктәй карлар коела.

*Кушымта:*
Яңа елның яңа карлары
Йомшак кына ява, сак кына.
Яңа елның яңа карыннан
Дөнья көлә, дөнья яктыра.

Яңа елның төне тылсымлы,
Чынбарлыкка ашсын теләкләр.
Җитәкләшеп атлыйк таңнарга,
Бергәләшеп типсен йөрәкләр.

*Кушымта.*

Яңа елның төне тылсымлы,
Серле булып утлар кабына.
Балачактан килгән әкият
Җыя безне чыршы янына.

*Кушымта.*

**Яралы кош**

*(И. Юзеев. «Гашыйклар тавы» спектакленнән)*

*Илдар Юзеев* сүзләре

Кыр үрдәген аттым очкан чакта...
Җаным әрни көн-төн: ник аттым?
Яралы кош сыман хәзер үзем –
Кайтыр юлларымны югалттым.

«Туган якларыңа кайт, кайт», – диеп,
Пар үрдәкләр тезелеп киткәндер.
«Кайта», – диеп өзелеп көткәндер дә,
Көтә-көтә түземе беткәндер.

Яралы кош, бәлки, кайтып җитәр...
Мин язмыштан инде ычкынмам.
Танырсыңмы-юкмы – мин булырмын
Кош тавышы белән кычкырган.

**Яратып откан җырым син...**

*(Т. Миңнуллин. «Яшьлек белән очрашу» спектакленнән)*

*Кәүсәрия Шәфикова* сүзләре

Яратып откан җырым син,
Җырламый ничек түзим?
Өзелми бит өметләрем,
Өзелми... ничек өзим?

Яратып откан җырым син,
Оныту мөмкин түгел.
Күзләрдә дә яздагыдай
Наз көтә минем күңел.

Яратып откан җырым син,
Яратып җырлыйм һаман.
Сүн, димә, сулар да сипмә,
Янасым килеп янам.

**Яшьлегем – ак пароход**

*(Т. Миңнуллин. «Яшьлек белән очрашу» спектакленнән)*

*Туфан Миңнуллин* сүзләре

Ак пароход йөзеп килә Иделләрдә,
Кул болгадым,
борылышлардан күренгәндә.
Каршылады аны акчарлаклар,
Куанышып уйнадылар алар,
Шатлыклы уйлар уятып күңелләрдә.

Ак пароход узып китте Иделләрдә,
Кул болгадым,
борылышларга күмелгәндә.
Озаттылар аны акчарлаклар,
Моңсу гына кычкырдылар алар,
Ямансу уйлар калдырып күңелләрдә.

*Г. Хугаев**. «МИНЕМ КАЙНАНАМ» музыкаль комедиясеннән**

**Яңгырлар яуганда**

*(Илдар белән Әлфиянең беренче дуэты)*

*Госман Әхмәтҗанов* сүзләре

*Илдар:*
Яңгырлар яуганда кичләрен урамда,
Безнең күк йөрүче гашыйклар аз була.
Иркәмне күрергә бүгенге яңгыр да
Ярдәм итәр әле аз гына.

*Кушымта, бергә:*
Без үтәрбез таныш урамнардан
Һәм урарбыз елга буйларын.
Иңне иңгә куеп, тын бакчада
Каршыларбыз таңның нурларын.

*Әлфия:*

Сулышлар киңәя, яктыра дөньялар,
Кулга-кул тотынып янәшә барганда.
Вәгъдәләр, кайнар ант сүзләре кирәкми,
Күңелләр шатлыктан тулганда.

*Кушымта, бергә.*

*Бергә:*
Синең һәр урамың, бульварың ягымлы,
Бу җәйге яңгырың да шифа күңелгә.
Әй туган калабыз – бәхетебез бишеге,
Кавыштырдың безне мәңгегә!

*Кушымта, бергә.*

* Татарчага Г. Әхмәтҗанов тәрҗемәсендә.
** Аккомпанементлар Г. Ротт тарафыннан язылды.

**Чәчәкләрдән бөркелә хуш ис**

*(Илдар белән Әлфиянең икенче дуэты)*

*Госман Әхмәтҗанов* сүзләре

*Илдар:*
Чәчәкләрдән бөркелә хуш ис,
Тирәк үсә су ярында.
Берсенә дә исем китми һич,
Янәшәмдә син барында.

*Әлфия:*
Чәчәкләрдән бөркелсен хуш ис,
Үссен тирәк су ярында.
Алар миңа шатлык кына ич,
Янәшәмдә син барында.

*Кушымта, бергә:*
Якты дөньяда йөрсәм дә,
Синсез көн юк миңа.
Яна йөрәк, ялкынлана,
Яна, яна, яна!

*Илдар:*
Нишләп соң һәрчак мәхәббәткә
Төрле киртәләр табыла?
Әмма шуңа карамастан ул
Көчлерәк булып кабына!

*Әлфия:*
Күкне болытлар капласа да,
Давыл чыкса да кай ара,
Елга диңгезгә юл ярган күк,
Йөрәк йөрәккә юл яра!

*Кушымта, бергә:*
Якты дөньяда йөрсәм дә,
Синсез көн юк миңа.
Яна йөрәк, ялкынлана,
Яна, яна, яна!

**Янәшәмдә син булмагач…**

*(Илдар ариозосы)*

*Госман Әхмәтҗанов* сүзләре

Янәшәмдә
Син булмагач,
Эшкә күңел ятмыйча,
Үз-үземне
Кайларга да
Куяр урын тапмыйча,
Урамнарны айкап урадым...
Урамнарны айкап урадым...
Үзем һаман бер уй уйладым:
Синсез минем бәхетем ким икән,
Синсез көнем кара төн икән,
Сагынуларым, зарыгуларым
Чынлап шашуларга тиң икән!

Күрә-күрә
Комлы ярда
Кояш алган парларны,
Бакчаларда
Күгәрчендәй
Тату гашыйк ярларны,
Елга тугайларын буйладым...
Елга тугайларын буйладым...
Үзем һаман бер уй уйладым:
Синсез минем бәхетем ким икән,
Синсез көнем кара төн икән.
Сагынуларым, зарыгуларым
Чынлап шашуларга тиң икән!

**Белсәң иде хисләремне...**

*(Әлфия җыры)*

*Госман Әхмәтҗанов* сүзләре

Йөрәктәге хисләремне
Уятма син, уятма син!
Күңелдәге хисләремне
Кузгатма син, кузгатма син!

Белсәң иде күкрәгемдә
Нинди дулкын чайкалганын.
Белсәң иде күкләремдә
Нинди нурлар балкыганын.

Яфрак яра, чәчәк ата
Бәхетемнең алмагачы.
Сайрый анда гүзәл таңда
Мәхәббәтем сандугачы.

**Кадерләгез кайнананы**

*(Илдар белән Гөлфинә дуэты. Финал)*

*Госман Әхмәтҗанов* сүзләре

Тормыш бик катлаулы нәрсә,
Тик шунда хикмәт:
Усал кайнаналарны да
Җиңә мәхәббәт!

Килер бәхет, көтү-көтү
Туар оныклар.
Гаилә бәхетен кайнанагыз
Бәладән саклар.

Кадерләгез сез бәхетне –
Тормыш канатын.
Кадерләгез кайнананы –
Гаилә канатын!

**Эчтәлек**


Авылым күле *(Х. Ибраһим. «Газиз ярым» спектакленнән)*. *Х. Ибраһим* сүзләре .........................
Ак чәчәкләр бүләк иттең *(Х. Ибраһим. «Газиз ярым» спектакленнән)*. *Х. Ибраһим* сүзләре .........
Ана сагышы *(Г. Зәйнашева. «Язмышлар һәм ялгышлар» спектакленнән)* ..................................
Әфганчылар җыры *(Г. Зәйнашева. «Язмышлар һәм ялгышлар» спектакленнән)*. *Г. Зәйнашева* сүзләре ...............................................................................................................
Балыкчы җыры *(Һ. Сафина. «Җыр дәвам итә» спектакленнән)*. *Һ. Сафина* сүзләре ..................
Бер сукмак салыр идек *(Ф. Яруллин. «Кызлар күңеле – тирән сер» спектакленнән)*. *Ф. Яруллин* сүзләре ...............................................................................................................
Гашыйклар тавы *(И. Юзеев. «Гашыйклар тавы» спектакленнән)*. *И. Юзеев* сүзләре .................
Гүзәлия җыры *(Г. Ахунов. «Утлар яна учакта» спектакленнән)*. *С. Сөләйманова* сүзләре .........
Далам – туган бишегем *(А. Балакаев. «Ана йөрәге» спектакленнән)*. *М. Хөсәен* сүзләре .............
Җиләккә бармам инде *(И. Юзеев. «Гашыйклар тавы» спектакленнән)*. *И. Юзеев* сүзләре ..........
Закир җыры *(Я. Ялунер. «Казан кызы» спектакленнән)*. *К. Булатова* сүзләре .........................
Зәкия җыры *(Г. Зәйнашева. «Гайфи бабай, өйлән давай!..» спектакленнән)*. *Г. Зәйнашева* сүзләре
Зөлфия җыры *(К. Әмиров. «Зөлфия» спектакленнән)*. *К. Әмиров* сүзләре ................................
И яна ла йөрәгем... *(Ш. Шаһгали. «Пожар» спектакленнән)*. *Ш. Шаһгали* сүзләре ...................
Йөрәгеңә якын итсәң... *(Һ. Сафина. «Җыр дәвам итә» спектакленнән)*. *Һ. Сафина* сүзләре .........
Йөрәк җыры *(Г. Ахунов. «Утлар яна учакта» спектакленнән)*. *С. Сөләйманова* сүзләре ............
Каерылмасын канатым *(Р. Батулла. «Каерылмасын канатым» спектакленнән)*. *Р. Мингалим* сүзләре ...............................................................................................................
Кайтыр идем *(Р. Хәмид. «Кайтыр идем» спектакленнән)*. *М. Шиһапов* сүзләре ........................
Каһарманнар *(Ш. Рәкыйпов. «Таңнар һаман матурмы?» спектакленнән)*. *Г. Әхмәтҗанов* сүзләре
Кемгә салыйм башны таңнарда?.. *(К. Финн. «Мәхәббәт хакына» спектакленнән)*. *Г. Ахунов* сүзләре
Көймәдә *(Х. Вахит. «Рәхим итегез!» спектакленнән)*. *Н. Арсланов* сүзләре .............................
Кулымдагы йөзегем *(Т. Миңнуллин. «Яшьлек белән очрашу» спектакленнән)*. *Т. Миңнуллин* сүзләре
Күңелләрдә безнең ак хыял *(Ф. Яруллин. «Кызлар күңеле – тирән сер» спектакленнән)*. *Ф. Яруллин* сүзләре .........................................................................................................
Кыр казлары артыннан *(И. Юзеев. «Кыр казлары артыннан» спектакленнән)*. *И. Юзеев* сүзләре
Мәхәббәттән аерылма *(В. Константинов, Б.Рацер. «Игълан буенча өйләнү» спектакленнән)*. *Г. Зәйнашева* сүзләре ...............................................................................................
Мин кызыл гөл булып шытармын *(М. Маликова. «Моңнар төште башыма» спектакленнән)*. *М. Маликова* сүзләре ...............................................................................................
Нефтьчеләр маршы *(Г. Ахунов. «Утлар яна учакта» спектакленнән)*. *С. Сөләйманова* сүзләре ...
Нигә килми, энкәй, хәбәрең?.. *(К. Әмиров. «Зөлфия» спектакленнән)*. *И. Юзеев* сүзләре ............
Ник йөрәккә саласың яра? *(А. Гыйләҗев. «Ефәк баулы былбыл кош» спектакленнән)*. *А. Гыйләҗев*

сүзләре ..........................................................................................................................
Өзелә үзәгем, өзелә... *(Ф. Яруллин. «Кызлар күңеле – тирән сер» спектакленнән)*. *Ф. Яруллин* сүзләре ..........................................................................................................................
Рәшит ариозосы *(К. Тинчурин, Г. Зәйнашева. «Назлы кияү» спектакленнән) Г. Зәйнашева* сүзләре
Салават җыры *(Һ. Сафина. «Җыр дәвам итә» спектакленнән)*. *Һ. Сафина* сүзләре ....................
Сәлим җыры *(Я. Ялунер. «Казан кызы» спектакленнән)*. *К. Булатова* сүзләре .........................
Синең күзләрең *(Р. Хәмид. «Кайтыр идем» спектакленнән)*. *М. Шиһапов* сүзләре ....................
Сок буйлары *(Һ. Сафина. «Җыр дәвам итә» спектакленнән Зәйнәп җыры)*. *Һ. Сафина* сүзләре ...
Су юлы *(Н. Әсәнбаев. «Мәхәббәт йолдызы» спектакленнән)*. *Н. Әсәнбаев* сүзләре ....................
Танышулар, кавышулар... *(Г. Зәйнашева. «Гайфи бабай, өйлән давай!..» спектакленнән)*. *Г. Зәйнашева* сүзләре ..........................................................................................................................
Театр *(Ш. Камал. «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектакленнән)*. *Г. Тукай* сүзләре .............................
Туган ил ул бер генә *(Т. Миңнуллин. «Безнең авыл Робинзоны» спектакленнән)*. *Т. Миңнуллин* сүзләре ..........................................................................................................................
Туган ягым каеннары *(И. Юзеев. «Олы юлның каены» спектакленнән)*. *И. Юзеев* сүзләре .........
Туй күлмәге *(Г. Ахунов, М. Шиһапов. «Кошның да үз оясы була» спектакленнән)*. *М. Шиһапов* сүзләре ..........................................................................................................................
Туй такмаклары *(Г. Ахунов. «Утлар яна учакта» спектакленнән)*. *С. Сөләйманова* сүзләре ........
Унҗиде яшем *(Г. Ахунов, М. Шиһапов. «Кошның да үз оясы була» спектакленнән)*. *М. Шиһапов* сүзләре ..........................................................................................................................
Ут салдың йөрәгемә *(Я. Ялунер. «Казан кызы» спектакленнән)*. *К. Булатова* сүзләре ...............
Уф, Алла!.. *(В. Константинов, Б.Рацер. «Игълан буенча өйләнү» спектакленнән)*. *М. Хөсәен* сүзләре ..........................................................................................................................
Хәмзин җыры *(И. Юзеев. «Сандугачлар килгән безгә...» спектакленнән)*. *И. Юзеев* сүзләре .......
Чакыру җыры *(Х. Вахит. «Кайда соң син?» спектакленнән)*. *Х. Вахит* сүзләре .......................
Чулпыларым бизи буемны *(С. Вилданова. «Чулпы моңы» спектакленнән)*. *С. Вилданова* сүзләре ..
Шәрифҗан җыры *(М. Ногман. «Кызыл чәчәк легендасы» спектакленнән)*. *М. Ногман* сүзләре .....
Якындагы ерак кешем син *(Һ. Сафина. «Җил давылга юрый» спектакленнән)*. *Һ. Сафина* сүзләре
Яңа ел вальсы *(Аманулла. «Кар калада Яңа ел» спектакленнән)*. *Аманулла* сүзләре .................
Яңа елның төне тылсымлы *(Аманулла. «Энҗебикә – кар кызы» спектакленнән)*. *Аманулла* сүзләре ..........................................................................................................................
Яралы кош *(И. Юзеев. «Гашыйклар тавы» спектакленнән)*. *И. Юзеев* сүзләре .........................
Яратып откан җырым син... *(Т. Миңнуллин. «Яшьлек белән очрашу» спектакленнән)*. *К. Шәфикова* сүзләре ..........................................................................................................................
Яшьлегем – ак пароход *(Т. Миңнуллин. «Яшьлек белән очрашу» спектакленнән)*. *Т. Миңнуллин* сүзләре ..........................................................................................................................

***Г. Хугаев.* «Минем кайнанам» музыкаль комедиясеннән**

Яңгырлар яуганда *(Илдар белән Әлфиянең беренче дуэты)*. *Г. Әхмәтҗанов* сүзләре .................
Чәчәкләрдән бөркелә хуш ис *(Илдар белән Әлфиянең икенче дуэты)*. *Г. Әхмәтҗанов* сүзләре ......
Янәшәмдә син булмагач... *(Илдар ариозосы)*. *Г. Әхмәтҗанов* сүзләре ......................................
Белсәң иде хисләремне... *(Әлфия җыры)*. *Г. Әхмәтҗанов* сүзләре ...........................................
Кадерләгез кайнананы *(Илдар белән Гөлфинә дуэты. Финал)*. *Г. Әхмәтҗанов* сүзләре ...............

Нотное издание

**Имашев** Масгут Габдрахманович

ВСЛЕД ЗА ДИКИМИ ГУСЯМИ

Казань. Татарское книжное издательство. 2013

На татарском языке

Ноталы басма

**Имашев** Мәсгут Габдрахман улы

КЫР КАЗЛАРЫ АРТЫННАН

Мөхәррире *В. Р. Камалиева*
Ноталарны җыючы һәм музыкаль мөхәррире *Г. Х. Беляева*
Рәссамы *А. Р. Хисмәтова*
Бизәлеш мөхәррире *Р. Х. Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *А. С. Газизҗанова*
Корректоры *Г. Г. Габдуллаҗанова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 20.06.2013. Форматы 60x90 $^1/_8$.
Шартлы басма табагы 12,0. Тиражы 1100 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс:(843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru. e-mail: info@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының күргәзмә-кибете. Тел.: (843) 519-45-13.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.